

# ИСМӘГЫЙЛЬ ГАСПРАЛЫ: ШӘХЕСЕ, МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ЮНӘЛЕШЕНДӘ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Эшне башкарды:** Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясенең 10 нчы сыйныф укучысы Сайфина Диләрә Айдар кызы

**Фәнни җитәкче:** татар теле һәм әдәбияты укытучысы Миннегулова Рәзинә Мәхмүт кызы

**Максат:** И. Гаспралы тормыш юлын, аның шәхес буларак формалашуын өйрәнү. Төрки милләтләрдә мәгърифәтчелек үсешенә йогынты ясаган фәнни эшчәнлеген барлау

**Бурычлар:** И. Гаспралы турында белемнәрне яңарту, туплау. Укучыларда мәртәбәле галимгә карата кызыксыну уяту, милли үзаң формалаштыру.

**Тикшеренү объекты:** Исмәгыйль Гаспралының (1851-1914) тормыш юлы һәм иҗтимагый-мәдәни эшчәнлеге

**Тикшеренү предметы:** Гаспралының мәгърифәтчелек концепциясе һәм «ысулы җәдит» программасы, «Тәрҗеман» газетасының төрки мәгърифәтчелек хәрәкәтендәге роле, шулай ук Гаспралының төрки халыкларның милли бердәмлеген төзүдәге концепциясе. Аның педагогик, әдәби һәм нәширлек эшчәнлеге

**Исмәгыйль Гаспралы – кырымтатар мәгърифәтчесе һәм сәясәтче, җәдитчелек хәрәкәтенә нигез салучыларның берсе. Мөселман халыклары арасында танылган шәхес, язучы, җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче, сәясәтче һәм нәшир.**






**Исмәгыйль Гаспралы (Гаспринский) 1851 елның 8 мартында Кырымдагы Гаспра авылы янындагы Хаҗикөйдә мирза гаиләсендә туа.**





Исмәгыйль Мортаза улы башлангыч белемне авыл мәктәбендә ала, аннан соң Воронеж шәһәрендә, Мәскәүдә кадетлар корпусында укый. Ләкин 14-15 яшьләрендә вакытта ул хәрби белем алуын калдырып, Идел, Дон елгалары, Азов диңгезе буйлап, Бахчасарайга Кырымга кайта.



Биредә ул атаклы Зынҗырлы мәдрәсәсендә берничә ел буена укытучылык итә.




**Аннан соң белемен күтәрү нияте белән Истанбулга китә. Истанбулдан Исмәгыйль Гаспралы Парижга барып чыга. 1871 елда Париж сорбоннасында лекцияләр тыңлый. Анда ул өч ел эшли. Эмиграциядәге русиялеләр белән очраша.**

**И. С. Тургенев янында эшләп тә ала, Гаспралы татар, төрек, гарәп, фарсы, француз, рус телләрен бик яхшы белә, бу белемнәре аркасында ул Парижда төрле телләрдә чыга торган газеталарда эшли, мәкаләләр яза, әдәби иҗат белән шөгыльләнүе дә шул чорда башлана.**






«Хужа субъян”
(“Балалар укытучысы” )




“Халык мәктәбе” дип аталган уку-укыту программасы





**Исмәгыйль әфәнде татар-төрки мәктәпләр өчен дәреслекләр яза, уку-укыту программалары төзи. 1884 елда үзе ачкан мәдрәсәдә гарәп әлифбасын яңа ысул белән укыта башлый, уку программасына дөньяви фәннәрне кертә, шунлыктан әлеге программа Россиянең башка җәдит мәктәпләре өчен үрнәк булып тора.**

**Исмәгыйль бәйнең "Ысулы җәдит" дигән программасы төркиләр арасында аеруча киң танылу ала. Балаларны язуга өйрәтүдә элеккедән килә торган традицион иске ысулдан - хәрефләр комбинациясен ятлаудан баш тарта, язуга хәреф-аваз системасы аркылы өйрәтүнең өстенлеген раслый. Бу зур методик, педагогик, график һәм лингвистик ачыш була.**




**Гаспралы, шулай ук, нәширлек эшчәнлеге белән шөгыльләнә, Бакчасарайда Коръән бастыру эшен җайга сала. 1904 елда Гаспралы Бакчасарайда китап басучыларның Россиядә беренче һөнәри берлеген оештыра.**



**1883 елның 10 апреле чын мәгънәсендә милли тарихыбызда көндәлек матбугат көне дип саналырга хаклы. Бу тарихи көн - беренче төрки газета “Тәрҗеман” (”Тәрҗемәче”) газетасының тәүге саны чыккан көн.**

**35 ел дәвамында һәр атнада 1-2 тапкыр чыгып барган "Тәрҗеман" газетасы бөтен дөньядагы төрки халыклар арасында тарала. Аны Кырымда, Истанбулда, Ташкентта, Бакуда һәм Казанда укыйлар. Газета мөселман булган милләтләрнең мәгърифәтен, мәдәниятен, әдәбиятын җанландыруда зур роль уйный.**



Галим һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани, алтын приискалары хуҗалары Закир һәм Шакир Рәмиевләр Гаспралының эшчәнлеген хуплыйлар. Акчурин кебек татар миллионерлары аңа булышып, матди ярдәм күрсәтеп торалар. Шиһабетдин Мәрҗанинең, Каюм Насыйриның, Муса Бигиевнең яңа әсәрләре "Тәрҗеман" газетасында басыла.










Язучы һәм галим буларак, Исмәгыйль Гаспралының “Дар эррәхәт мөселманнары”, “Көн туды” кебек күләмле повесть һәм романнары, “Мәзһәбе иштиракыйун” кебек көн кадагына суккан публицистик хезмәтләре дә “Тәрҗеман”да басылалар. Бу әсәрләр мәгърифәтченең бөтен төрки дөньясына ташлаган “Телдә, фикердә, эштә берлек” дигән чакыруын куәтли.









**Исмәгыйль бәй Гаспралының төрки милләтләр бәхете хакына башкарган җәмәгать эшләренә күз салсаң, аның активлыгына хәйран каласың. Беренче рус инкыйлабы елларында, мәсәлән, И. Гаспралы Кырым игенче-крестьяннарының ике съездын үткәргән, 700 дән артык делегат катнашкан бу съездларның мәҗлесләрендә җир мәсьәләләренә багышланган төрле чыгышлар ясый. Рәсәй тарихында иң беренчеләрдән булып, И.Гаспралы 1904 елда Бахчасарайда матбугат хезмәткәрләренең һөнәр-кәсеп оешмасын (профсоюзын) төзи.**




REVUE DU MONDE MUSULMAN

Publiée par

LA MISSION SCIENTIFIQUE DU MAROC

DÉCEMBRE 1914 VOLUME XXIX

LES MUSULMANS FRANÇAIS ET LA GUERRE

Adresses et témoignages de fidélité des chefs musulmans et des personnages religieux.

I. AFRIQUE OCCIDENTALE

II. ALGÉRIE ET TUNISIE

III. MAROC

ERNEST LEROUX, ÉDITEUR, 28, RUE BONAPARTE (VI^e)

TOUS DROITS RÉSERVÉS

- **Бөтенроссия мөселманнарының I, II, III корылтайларында катнаша; II корылтайда «сыйнфый ызгышлар»га каршы чыга, «мөселманнарның мәдәни үсешен тәэмин итү»не яклый.**
- **1910 елда Парижның «La Revue du Monde Musulman» («Мөселман дөньясы») журналы Гаспралыны Нобель премиясенә тәкъдим итә.**

**“Ник сөелгән Исмәгыйль һәм моңлы җырчыбыз Тукай”? Эшләгәннәр армый-талмый, күп тырышлыклар һаман”, -**дип яза 1916 елда шагыйрә Зәйнәп Сәгыйдә.



Тукай исә Гаспралы чыгарган газетаны ***“Милләт дәртенә тәрҗеман”, ягъни милләтнең авыруын әйтеп бирүче һәм аның кайгы-хәсрәтен аңлатып бирүче*** дип атый.



***“Тәрҗеман”га мәхәббәтем вә ихласлыгым камил иде***, - дип яза Р. Фәхретдин “Сәлимә яки гыйффәт” (1898) романындагы төп герое исеменнән. - ***Болай мәхәббәт итүемдә үземне хаклы дип саный идем. Чөнки бу могтәбәр газета үз телебездә чыккан нәшрият әдәбиятыбызның юлбашчысыдыр. Иң мәгълүматсыз бер халыкка башлап гыйлем вә мәгърифәт нәшер әйләмәк дөньяда беренче дәрәҗә мөшкел бер хезмәт икәне мәгълүмдер. “Тәрҗеман” исә бу өлкәдә, дөнья чишә алмас дәрәҗәдәге авырлыкларны күтәреп, юлында тугры калды”,*** - ди.



**Кулланылган әдәбият**

1. Госманов М. Төрки-татар мәгърифәтчелек тарихында Исмәгыйль Гаспралы: бер идеянең тантанасы һәм фаҗигасе // Казан утлары. 2001. № 3.

2. https://tatarica.org/tat/razdely/istoriya/novoe-vremya/personalii/gaspraly-ismgyjl

3. http://100tatarstan.ru/structure/profile/rukhim- mktptn-universitetlarga

4. Татар милли педагогикасы: Югары һәм урта педагогика уку йортлары өчен уку ярдәмлеге /Р.Х. Шәймәрданов, Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. - Казан: Мәгариф, 2007. - 399б.

5. “Мәдәни җомга” № 22 (09.06.2016)

6. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / [төз. Р.Ф.Рахмани]. - 3 т. : XIX йөз / фәнни мөх. Ф.Г. Галимуллин. - Казан: Тат. кит. нәшр., - 2015. - 551 б.